ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ АККҮЗ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ ЖИТӘКЧЕСЕ
423744, Аккүз авылы,
Үзәк ур.,1 нче йорт. Тел.3-44-42

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО
КОМИТЕТА АККУЗОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
423744, село Аккузово,
ул. Центральная,дом 1,

КАРАР
22.04.2020

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№ 12

Актаныш муниципаль районы Аккүз авыл җирлеге 22.10.2019 №17 "Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының "Аккүз авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибен раслау хакында" Башкарма комитет карарына үзгәрешләр кертү турында

Бюджет кодексының 47.2 маддәсенең 4 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 06 маендагы 393 номерлы карары, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Аккүз авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 48 статьясы нигезендә расланган, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенә гомуми таләпләр нигезендә, Актаныш муниципаль районы Аккүз авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Аккүз авыл җирлеге 22.10.2019 №17 " Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы "Аккүз авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибен раслау хакында" Башкарма комитет карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 2 пунктында "таможня эше " сүзләрен "таможняны җайга салу" сүзләренә алмаштырырга.

1.2. 1 нче кушымтаның 3 пунктында:

- 2 пунктчада «бюджетка түләнмәгән түләүләр буенча бурычлар өлешендә» сүзләрен «әлеге Тәртип нигезендә кредиторлар белән исәп - хисаплар тәмамланганнан соң түләнмәгән бюджетка түләүләр буенча бурычлар өлешендә» сүзләренә алмаштырырга;

- түбәндәге эчтәлекле 2.2 пунктчасы белән тулыландырырга:

- "Бөлгенлек (банкротлык) турында" 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, индивидуаль эшкуар булмаган гражданны банкрот дип тану - күрсәтелгән Федераль закон нигезендә кредиторлар белән исәп-хисаплар тәмамланганнан соң түләнмәгән бюджетка түләүләр буенча бурычлар өлешендә;

- 1 нче кушымтаның 3 пунктчасында "оешма мөлкәтенең җитәрлек булмавы һәм (яки) мөмкин булмау сәбәпле аларның түләнгән" сүзләрен "оешма мөлкәтенең җитәрлек булмавы һәм (яки) мөмкин булмавы аркасында аның түләнгән " сүзләренә алмаштырырга;

- 1 нче кушымтаның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4) амнистия турында яисә җәзага тартылганнарга карата штраф рәвешендә яисә суд тарафыннан карар кабул итү рәвешендә җәза бирү турында актлар куллану, аның нигезендә бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтү мөмкинлеген югалта;

- 1 нче кушымтаның 5 пунктчасындагы беренче абзацында "3 һәм 4 пунктларында каралган нигезләр" сүзләрен "3 һәм 4 пунктларында каралган нигез” сүзләренә алмаштырырга.

1.3. 1 нче кушымтаның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- 4. Әлеге статьяның 1 пунктында каралган очраклар белән беррәттән, административ җәза билгеләү турында карар чыгарган судья, орган, вазыйфаи зат тарафыннан административ җәза билгеләү турында Россия Федерациясе кодексында каралган очракларда административ җәза билгеләү турындагы карарны үтәүне туктату турында карар чыгарылган булса, түләнмәгән административ штрафлар түләтүгә өметсез дип таныла.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы Аккүз авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Аккүз авылы, Үзәк урам, 1 нче йорт адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы Аккүз авыл җирлегенең рәсми сайтында халыкка игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Аккүз авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Г.И.Имамова